СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 349 от 29.04.2020

на № __ от ________

# К А Р А Р

Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору һәм түләүдән азат итү шартлары турында

“Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм вакытына таләпләрне билгеләү турында” 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, “Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында” 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы һәм 821-р номерлы күрсәтмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәт шартнамәләре буенча узган чорга аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендаторларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору мөмкинлеге бирергә.

2. Саба муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп торуның беркетелгән шартларын расларга.

3. Өстәмә килешүләр 2020 елның апрель – июнь айларында аренда түләвен кичектереп торуны һәм аны 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда килешүендә каралган срокларда тигез өлешләрдә түләүне, шулай ук аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә кичектереп тору бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш дип билгеләргә.

4. Авиайөкташу һәм пассажирлар йөртү, аэропорт эшчәнлеге, автойөкташу һәм пассажирлар йөртү, мәдәният, ял итү һәм күңел ачуны оештыру, физкультура-савыктыру эшчәнлеге һәм спорт, туристлык хезмәтләре, кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы, өстәмә белем бирү, дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре, конференцияләр һәм күргәзмәләр оештыру, халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (ремонт, юу, химчистка, чәчтарашханә һәм матурлык салоннары хезмәтләре күрсәтү) өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы арендаторларны - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларын аренда түләүләрен түләүдән азат итәргә , мондый арендаторларны 2020 елның апрель – июнь айларында Саба муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү. Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү, әгәр аренда шартнамәсендә Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне, күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында, арендага бирү каралган булса һәм эшчәнлекнең күрсәтелгән төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслаучы документлар булганда гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән аренда түләүләреннән азат итү:

– әлеге карар нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге, әлеге карарның 4 пунктында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган, күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорга аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендаторларга карата гамәлгә ашырыла.

– әгәр аренда шартнамәсендә Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне, күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында, арендага бирү каралган булса һәм эшчәнлекнең күрсәтелгән төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслаучы документлар булганда гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Саба муниципаль районы Башкарма комитетына Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән соң 7 эш көне эчендә, Саба муниципаль районы муниципаль

милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, 2020 елның апрель – июнь айлары өчен, мондый арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән вакытка, кичектерелгән аренда түләүләрен 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча түли башлау белән, аренда түләүләрен кичектерүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү;

б) авиайөкташу һәм пассажирлар йөртү, аэропорт эшчәнлеге, автойөкташу һәм пассажирлар йөртү, мәдәният, ял итү һәм күңел ачуны оештыру, физкультура-савыктыру эшчәнлеге һәм спорт, туристлык хезмәтләре, кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы, өстәмә белем бирү, дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре, конференцияләр һәм күргәзмәләр оештыру, халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (ремонт, юу, химчистка, чәчтарашханә һәм матурлык салоннары хезмәтләре күрсәтү) өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән соң 7 эш көне эчендә, мондый арендаторларны 2020 елның апрель – июнь айларында Саба муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү.

в) Саба муниципаль районының рәсми сайтында, арендаторлар - кече эшмәкәрлек субъектлары өчен, әлеге карар үз көченә кергән көннән 3 эш көне эчендә, әлеге пунктның “а” пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Саба муниципаль<br>районы Башлыгы Р. Н. Минниханов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары**

1. 2020 елда күчемсез мөлкәтне файдаланган өчен каралган аренда түләвен түләүне кичектереп торуның әлеге шартлары, 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан, “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” Федераль законның 11 статьясы нигезендә, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган, яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә халнең начараюы шартларында иң күп зыян күргән, Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм шәхси эшкуарлар булган арендаторлар белән Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнче төзелгән күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләренә карата кулланыла. (алга таба – аренда килешүе, кичектерү).

2. Кичектерү, торак биналардан тыш, күчемсез милеккә карата бирелә.

3. Кичектерү ,Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгәннән соң, 2020 елның 1 октябренә кадәр, түбәндәге шартларда бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк башкарылмыйча һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, айга бер тапкырдан да ешрак булмыйча, күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләргә бүленеп түләнергә тиеш;

б) кичектерү тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булу срогына һәм Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елның 1 октябренә кадәр югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булуы туктатылган көннән алып тиешле чорда аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый;

г) кичектерү бирелүгә бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне арендага бирүче тарафыннан билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектерү бирелә торган аренда түләве күләме яклар килешүе буенча киметелергә мөмкин;

е) әгәр аренда шартнамәсендә арендатордан коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яисә) арендалана торган мөлкәтне тотуга чыгымнарны аренда түләвенә кертү каралган булса, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган чорда арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яисә) мондый чыгымнар тотудан азат ителгән очраклардан тыш, күрсәтелгән өлеш буенча аренда түләвен кичектерү бирелми.

4. 3 пунктта каралган кичектерү шартлары, мондый килешүне төзү датасына бәйсез рәвештә, кичектерү турында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләргә карата кулланыла.